**С.К.ГИМАТДИНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ОСИНОВО ГИМНАЗИЯСЕ**

# МИНЕМ ШӘҖӘРӘМ

**ПРОЕКТ**

**2025-2026 уку елына**

## Аңлатма язуы

Нәсел-нәсәбегезне белегез,
кардәшләрегезгә барыгыз,
чөнки бергә яшәсәгез дә,
өзелгән туганлыкта якынлык юк,
еракта торсагыз да, йөрешкән
туганлыкта ераклык юк.
“Мең дә бер хәдис” китабыннан

Тарих һәм халык... Бер-берсеннән аерылгысыз төшенчәләр болар. Һәр ил, шәһәр, авылның, хәтта аерым бер нәселнең үзенчәлекле үткәне, тарихы бар. Борынгы заманнардан ук татар халкында ата-баба нәселен, җиде буынны белү изге бурыч булып саналган. Мөселман булган кеше үзенең әти һәм әнисе ягыннан булган җиде буын бабалары рухына дога укырга тиеш була. Шуңа күрә дә ил агалары – аксакаллар үзләренең нәсел агачын төзегәннәр һәм үз ыруларының кабатланмас тарихын язып барганнар, шәҗәрәсен төзегәннәр, киләчәк буынга ядкарь - истәлек калдырганнар. Әйе, зирәк булган өлкәннәр – буыннар чылбырын өзелмәслек нык җепләр белән бәйләргә тырышканнар.

Җиде буын, буыннар бәйләнеше, шәҗәрә... Бу сүзләр тирән мәгънәгә ия. Гади генә әйткәндә, **шәҗәрә ул** – нәсел-ыруның кемнән башланып, ничек тармакланып китүен күрсәткән кульязма истәлек. Анда ата-бабалар исемлеге, нәсел тарихына бәйле вакыйгалар теркәлгән. Фәнни нигездә билгеләмә биргәндә, **шәҗәрә** – генеалогик язма – туган-тумачалык, һәр шәхеснең тормышы һәм кылган хезмәтләре хакында мәгълүмат алып була торган тарихи чыганак ул.

Өлкән буын белән яшьләр арасындагы мөнәсәбәт, рухи элемтә – мәңгелек мәсьәлә ул. Яшьләрне тәрбияләүдә өлкәннәр тәэсире бик кирәк. Шул очракта гына яшь кешегә үз нәсел шәҗәрәсен үзләштерү өчен уңай шартлары туа.Нәсел чылбырында үзенең булуын тою кешедә яхшы гамәлләр белән горурлану тойгысы, шуңа лаек булырга тырышу теләге тәрбияли.Моның өчен яшьләрнең зирәк һәм тәҗрибәле өлкәннәр киңәшенә һәм өйрәтүләренә

колак салуы, алардагы уңай сыйфатларны үзләштерүе кирәк.Өлкәннәргә хөрмәт алар белән бергә яшәгәндә күбрәк чагылыш таба.Хәзер шәһәрдә генә түгел, авылларда да ата- анасы, улы, оныгы белән бергә яшәү сирәк күренешкә әйләнеп калды. Гаилә әгъзалары арасында аралашу да тансык бер шөгыль була бара. Бу хәл буыннар чылбырының йомшаруына, кардәшлектә аралашу өзелүгә китерә, гаилә традицияләренең, гореф – гадәт һәм йолаларның буыннан – буынга күчемлелеген тоткарлый.Шуңа күрә монда иң мөһиме шул :һәр әби- бабай һәм ата- ана үз баласына ике якның да нәсел шәҗәрәсендәге бабаларның тормышы, эш- гамәлләре турында сөйләп, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләргә, гадәт- йолаларны балаларга тапшырырга тиеш.

Менә шуңа күрә дә Осиново гимназиясендә “Минем шәҗәрәм” проекты эшләп килә.

**Актуальлеге**: Үзенең нәсел-нисбәтен белү, аларның шөгыльләрен барлау бүген бик актуаль.

**Максаты**: Җиде буынга кадәр үз нәселен белү .

**Бурычлар:**

1.Нәселемнең каян килеп чыкканлыгын өйрәнү.

2.Буыннар арасындагы бәйләнешне барлау.

3.Гаилә шәҗәрәсен булдыру.

## Төп өлеш

Шәҗәрә
Туган туфрагыма күмелеп калган
Гомер агачымның тамырлары.
Ул тамырлар җирдә сабыр гына
Көтеп ята безнең кагылганны.
Ф.Яруллин

Туган җир,туган туфрак, туган нигез .... Бу тирән мәгънәле төшенчәләр һәркем өчен изге һәм кадерле нәрсәләрне аңлата. Кеше кайда гына булмасын, нинди генә урыннарны күреп сокланмасын,аның күңелен һәрвакыт газиз җире, туган нигезе үзенә тарта.Биредә аның эти-әнисе гомер итә,нәселдәш туганнары яши,ерак бабаларының каберләре, аларның истәлекләре саклана.

Кеше җирдә ни өчен яши ? Үзенең кыска гына гомере эчендә ул барысына да өлгерергә, барын да танырга, белергә, үзе эшләп калырга, сөенергә, шатланырга, кайгы-хәсрәтне җиңеп чыгарга һәм үзе турында киләчәк буынга якты истәлек калдырырга тиеш. “Әгәр үлгәч тә искә алсыннар дисәң,игелекле нәсел һәм эчтәлекле китап язып калдыр”,- дигән борынгы акыл ияләренең берсе.Аның бу гыйбрәтле сүзләрен ничек аңларга соң? Игелекле нәсел калдыр – бу сүзләр, минемчә кешегә икеләтә бурыч йөкли. Беренчедән, нәселең игелекле булсын дисәң, үзең дә игелекле булырга тиешсең – буыннар чылбырын тоташтыручы нәсел шәҗәрәсе. Шушы чылбыр өзелмәсә, һәрбуынның эшләре турында тарих битләренә күп мәгълүмат язылып киләчәк буыннарга тапшырыла барачак. Димәк,без дә аның битләрен актарабызһәм үзебез дә бу китапны язабыз.

“Һәр кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш, -диләр борынгылар.Шулвакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең үз халкының үткәнен яхшы белә”.Халкыбызда борын- борыннан җиде буын әби-бабаңа кадәр үз нәселеңнең буыннарын күңелдән белү һәм нәсел шәҗәрәләрен кәгазьгә теркәү гадәте булган.Шәҗәрәләр белү, язып бару-

матур һәм борынгы гадәт. Алар аркылы кешеләр ата- бабаларының дәвамчысы булуларына төшенгәннәр.

Нәрсә соң ул шәҗәрә? Гарәп теленнән кергән “шәҗәрә ”сүзе агач дигән мәгънәне белдерә.Буыннарның өзлексез алмашынып торуын ботаклы агачка охшатып төзелгән шәҗәрәләр язу,нәсел шәҗәрәсен төзү гадәте борынгы заманнар да ук халыкларда билгеле булган.

**Эзләнү методлары**

1.Туганнардан сораштыру

2.Гаилә архивларын,документларны өйрәнү

Эш планы:

| срогы | чаралар | катнашалар | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 2025-2026 | Норматив документларны өйрәнү | Укучылар,укытучылар,эти-эниләр | Сыйныф җитәкчеләре |
| 2025-2026 | Төрле язучыларның шәҗәрәләрен өйрәнү | Укучылар,укытучылар,эти-эниләр | Туган(татар),рус теле укытучылары |
| 2025-2026 | Гаилә альбомнарын өйрәнү | Укучылар,укытучылар,эти-эниләр | Сыйныф җитәкчеләре |
| 2025-2026 | Документлар буенча гаилә тарихларын өйрәнү | Укучылар,укытучылар,эти-эниләр | Сыйныф җитәкчеләре |
| 2026 | Гаиләнең шәҗәрәсен төзү | Укучылар,укытучылар,эти-эниләр | Сыйныф җитәкчеләре |

**Йомгаклау.**

Үткән тарихка сәяхәт кызыклы да, катлаулы да эш. Үткәннәрне барлау, киләчәк өчен зур байлык калдыру ул.